**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

КАРАР

2021 елның «03» февраленнән № 44

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы муниципаль милкендәге күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектереп тору яки өлешчә түләүдән азат итү шартлары турындагы» 08.05.2020 № 119 карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы муниципаль милкендәге күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектереп тору яки өлешчә түләүдән азат итү шартларына үзгәрешләр кертү турында

«Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 1 апрелендәге 98-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күчемсез милекне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләве шартларына һәм срокларына таләпләр билгеләү турында» 2020 елның 3 апрелендәге 439 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт милкендә булган күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен түләүне кичектереп тору шартлары турында» 2020 елның 22 апрелендәге 314 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22.04.2020ел №820-р, 22.04.2020 ел, № 821-р боерыклары нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы муниципаль милкендә булган күчемсез милекне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектереп тору яки өлешчә азат итү шартларына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктка түбәндәге эчтәлекле тәкъдим өстәргә: "Арендатор икътисадый эшчәнлекнең төп яки өстәмә төрләре буенча билгеләнә, алар турында мәгълүмат Юридик затларның бердәм дәүләт реестрында яисә индивидуаль эшкуарларның бердәм дәүләт реестрында 2020 елның 1 апреленә булган мәгълүматлар буенча»;

3 пунктта:

беренче абзацтагы "2020 елның 1 октябренә кадәр» сүзләрен «2021 елның 1 гыйнварына кадәр" сүзләренә алмаштырырга»;

"б» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) кичектерү тиешле чор өчен аренда түләве күләмендә бирелә»

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының җирле үзидарә органнарына муниципаль милекне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектереп тору яисә өлешчә түләүдән азат итүне хәл иткәндә, әлеге карарга таянып эш итәргә тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасына йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фәсахов